**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №79-40 «14» декабрь 2017 ел

Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында сайланулы вазыйфаларны даими нигездә биләүче затлар өчен гарантияләр турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы, "Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә даими нигездә вәкаләтләр башкаручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.Р. Шәрипов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге Советының
2017 елның 14 декабрендәге
79-40 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлегендә даими нигездә вәкаләтләр башкаручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының даими нигездә вәкаләтләр башкаручы Сарлы авыл җирлеге депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм күрсәтелергә мөмкин.

2. Матди ярдәм муниципаль вазыйфаны биләгәннән соң кимендә 3 ай узгач түләнә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы карары буенча матди ярдәм өстәмә рәвештә (алга таба-өстәмә матди ярдәм) түбәндәге күләмнәрдә түләнергә мөмкин:

туган көне уңаеннан - бер мең сум;

50 еллыгы, 55 еллыгы, 60 еллыгы, 65 еллыгы уңаеннан - биш мең сум;

авыр авыру уңаеннан - биш мең сум;

килгән матди зыянны яисә сәламәтлеккә зыян килүне каплау максатларында табигый бәла-казага яисә гадәттән тыш хәлгә бәйле рәвештә - җиде мең сум; ире (хатыны) яки балалары каты авырган очракта - биш мең сум;

үлем уңаеннан;

а) хатыны (хатыны) яки балалары - ун мең сум;

б) ата-аналары - биш мең сум.